| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЕЛАБУЖСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 24.08.2023 1252 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Төбәк оператор счетында Алабуга шәһәренең күпфатирлы йортларындагы уртак мөлкәткә карата капиталь ремонт фондын формалаштыру турында» 2014 елның 17 апрелендәге 414 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә һәм гамәлдә булган законнарда билгеләнгән срокларга туры китереп күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау турында күпфатирлы йорттагы бина милекчеләре тарафыннан кабул ителгән карарлар белән бәйле рәвештә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Төбәк оператор счетында Алабуга шәһәренең күпфатирлы йортларындагы уртак мөлкәткә карата капиталь ремонт фондын формалаштыру турында» 2014 елның 17 апрелендәге 414 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә 1 нче кушымтадагы билгеләнгән капиталь ремонт фондын формалаштыру буенча күпфатирлы йортлар исемлеген тулыландырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
24.08.2023ел

1252 карарына 1 нче кушымта

**Капиталь ремонт фондын формалаштыру буенча**
**күпфатирлы йортлар исемлеге**

| № | Муниципаль берәмлек | Адресы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Алабуга районы | Алабуга шәһәре, Мәрҗани урамы, 7 В нче йорт |
| 2. | Алабуга районы | Алабуга шәһәре, Сөембикә урамы, 38 нче йорт |